
Журнал „Мирас"
№ 7, 2007.



# УКЫТУ-ТӘРБИЯ СИСТЕМАСЫНДА ЯҢА ЮНӘЛЕШЛӘР

*(Мирас ядкәре)*

Безнең чор — яңача фикерләү, фәндә, техникада, җитештерүле хезмәттә яңа ачышлар ясала торган заман. Бу укыту-тәрбиягә, ягъни педагогикага да нык кагыла. Яңалыкларны, казанышларны укыту-тәрбия эшендә куллану өчен һәр укытучыга яңа педагогик төшенчәләрнең асылын, үзенчәлекләрен белү бик мөһим. Әлеге бурычны гамәлгә ашыруга ярдәм күрсәтү максатында бу язмада педагогикадагы яңа күренешләрнең кайберләренә кыскача тукталып үтәбез.

Интегральләштерелгән укыту төшенчәсе латинча «бербөтен», «аерым өлешләре бәйләнгән» дигән мәгънәдәге сүзләрдән ясалган. Ул педагогикага математика, физика, биологиядән кергән. Төрле фәннәрнең эчтәлеген бергә бәйләп, берләштереп үткәрелә торган интегральләштерелгән дәресләр кайбер укытучылар тәҗрибәсендә уңышлы кулланыла.

Дәрес-панорама («Панорама» грекча бөтенесе, барлыгы, тулысынча һәм күренеш дигәнне аңлата). Үз эченә күп төрле, киң күләмле вакыйгаларны һәм фактларны сыйдырган (мәсәлән, географиядә теге яки бу төбәкне, илне һәрьяклап тасвирлаган) дәрес «дәрес-панорама» дип атала. Шуны да әйтергә кирәк, кайбер очракта шушындый яңа атамалар һәм төшенчәләр белән мавыгып китүләр дә бар. Мәсәлән, «дәрес-марафон», «дәрес-КВН», «дәрес-ярминкә», «дәрес-пресс-конференция» һ.б. Аларны чагыштырып карасаң, барысы да уен, күңел ачу белән бәйләп алып барыла торган һәм укытуның төрле формаларын берләштерергә омтылышлы дәресләр булуы ачык күренә.

Дәрес-блок. «Блок» — ул берничә кисәкне берләштергән җыелма мәгънәсендә. Педагогикада укытуның, белем бирүнең берничә формасын берләштергән дәресне «дәрес-блок» дип йөртә башладылар. Мәсәлән, лекция, мөстәкыйль эшләү, практик эшләр башкару, белемнәрне тикшерү һәм башка максатларны берләштергән дәресләр шулай аталалар. Андый дәресләр, гадәттә, өлкән сыйныфларда үткәрелә. Алар вакыт ягыннан да 3—4—5 дәресне берләштерәләр.

Монда «блок» сүзен кулланмаска да мөмкин булыр иде. Дәресләрнең берничә төрен берләштереп үткәрелә торган укыту формалары педагогикада, русчадагы «комбинированные уроки»-ны күчереп, берләштерелгән дәресләр исемендә киң таралган.

Адаптацияләнгән (җайлаштырылган) укыту төшенчәсе ла-

тинча яраклашу, җайлашу мәгънәсендә ясалган. Бу төшенчә биологиядән кергән. Социологиядә исә ул шәхеснең җәмгыять таләпләренә яраклашуын аңлата. Ә педагогикада бу төшенчәне укытуның эчтәлеген, формаларын, ысулларын һәм алымнарын укучыларның үсеш үзенчәлекләренә һәм белем дәрәҗәләренә яраклаштыру, җайлаштыру мәгънәсендә кулланалар. Мәсәлән, чит телләрне өйрәткәндә текстларны җиңелләштерүне адаптация дип атыйлар.

Уку-укытуны оптимальләштерү (латинча иң уңайлы, иң яраклы дигәнне аңлата), балаларның мөмкинлекләренә туры китереп, иң уңайлы, яраклаштырылган шартлар булдыру дигән сүз.

Активлаштыру — киеренке эшчәнлек, көч куеп эшләү. Укучының танып белү эшчәнлеген көчәйтү, киеренкелеген арттыру яки укытучының эш формаларын, ысулларын һәм алымнарын нәтиҗәлерәк итү, шулар ярдәмендә укучының эшчәнлеген көчәйтү.

Дифференциаль укыту — латинча «бүлү», «аеру» дигән сүз нигезендә барлыкка килгән төшенчә. Укучыларның сәләтен, мавыгуларын, кызыксынуларын искә алып, аларны төркемнәргә бүлеп укыту: физика, математика, химия, биология, тел, әдәбият, тарих һ.б. фәннәрне тирәнтен өйрәнү мәктәпләре, сыйныфлар ачу дифференциаль укытуга керә.

Педагогик аралашу. Ул — педагог һәм укучы, педагог һәм ата-ана, педагог һәм үз хезмәттәшләренең бәйләнеше, аралашуы. Хәзерге вакытта педагогик аралашу культурасы, аның эчтәлеге, кагыйдәләре ныклап өйрәнелә, булачак укытучыларны һәм эшләүче педагогларны дөрес аралашуга өйрәтү оештырыла.

Яңа төшенчәләрнең күбесе педагогикага хәзерге көнкүрешкә аеруча нык тәэсир ясый башлаган икътисадтан һәм техникадан килеп керә. Бүген халык мәгарифенең икътисады, укыту техникасы һәм технологиясе, укытуны компьютерлаштыру һ.б. мәсьәләләрне өйрәнү-тикшерү эше алып барыла. Шуңа бәйле рәвештә яңа педагогик төшенчәләр дә туа: «педагогик технология», «педагогик техника» төшенчәләре дә кулланышка кереп бара.

Нәрсә соң ул «педагогик технология»? Технология грекча осталык дигәнне аңлата. Техникада бу сүз «материалларны эшкәртү, әйберне җитештерү-ясау ысулларының эзлекле җыелмасы» дигән мәгънәне белдерә. Ә педагогикада ул инженерлык алымнарын, карашларын уку-укыту процессында куллану була. Шулай ук төрле техник чаралардан (кино, телевизор, радио, магнитофон язмалары һ.б.), программалаштырылган укыту ысулларыннан файдалану да уку-укыту технологиясенә керә.

Америка колледжлары һәм университетларында 1940 елларда ук педагог-технологлар эзерли башлыйлар. Соңрак, техникадагы үсешләр нәтиҗәсендә, «педагогик технология» төшенчәсенең дә эчтәлеге киңәя. 1980 еллардан башлап укыту технологиясенә компьютерлар да кертелә.

Соңгы елларда «педагогик технология» төшенчәсе тагын да киңрәк мәгънәгә ия була бара. Мәсәлән, АКШтагы Педагогик

ассоциация һәм технологияләр берләшмәсе аңлатканча, педагогик технология укытуны, белемнәрне үзләштерүне, идея-фикерләүне, төрле чараларны, ысулларны бергә куллануны планлаштыруны һәм гамәлгә ашыруны үз эченә ала. Хәзер кайбер илләрдә педагогик технология үзәкләре эшли. Аларның бурычы — укыту процессын, яңалыклар кертеп, даими камилләштерә бару, яңа дәреслекләр, укыту өчен видеофильмнар, компьютерларга программалар һ.б. ярдәмлекләр төзү.

Педагогик техника — укытучының эшендә укыту-тәрбия ысулларын, алымнарын һәм чараларын югары нәтиҗәле куллану өчен кирәкле белем һәм күнекмәләр җыелмасы. Педагогик техника шул ук вакытта педагогик осталыкның төп өлеше дә. Аңа түбәндәге сыйфатлар керә:

— педагогик аралаша белү;

— үзеңнең игътибарың, эчке тойгыларың белән идарә итә алу;

— үз-үзеңне тота белү;

— дөрес, матур, җәлеп итәрлек итеп сөйли алу;

— кул хәрәкәтләре, гәүдә тотышы белән дөрес файдалана белү һ.б.

Укытучы-тәрбиячеләр үзләрендә педагогик техника булдыру өчен даими эшлиләр. Әлбәттә, аның төп нигезләре педагогия училищеларында, институтларында үзләштерелә.

Соңгы вакытта педагогикадагы яңа төшенчәләрнең барысын бер сүз белән берләштереп, «инновация» дип атау гамәлгә кереп бара. Инновация инглизчә «яңалык, үзгәреш кертү, яңарту» дигән мәгънәдә кулланыла. Укыту-тәрбиянең моңа кадәр билгеле булмаган төрләрен, ысулларын, чараларын гамәлгә кертеп, эш үзгәртеп корыла, тагын да камилләштерелә. Хәзер ул аеруча җанланды. Укытучылар, тәрбиячеләр, галимнәр укыту-тәрбиянең заманча системасын булдырырга омтылалар, яңача эчтәлеген, форма һәм ысулларын, чараларын эзлиләр, иҗади эшләргә тырышалар.

Педагогик эшчәнлектә иҗадилык нәрсә соң ул?

Педагогикада иҗадилык — укыту-тәрбия системасын яңарту, яңа идеяләр, ысуллар, чаралар эзләп табу. Мондый югары дәрәҗәдәге иҗадилык, ачыш ясау сыйфаты бик аз укытучыларга гына хас. Әмма һәр укытучы диярлек үз эшенә яңалыклар кертергә тырыша.

Укытучыларның эш тәҗрибәсенә күз салсак, хәзерге вакытта педагогикада яңалыклар кертү төп өч юнәлештә барганын күрербез:

1. Укыту-тәрбияне оештыруның төрләрен яңарту, яңа типтагы уку йортлары (гимназия, лицей, колледж һ.б) ачу. Элек булып та, соңгы елларда онытыла барган уку йортларын яңадан тергезү.

2. Яңа (камилләштерелгән) уку-укыту планнары һәм программаларын гамәлгә кертү.

3. Укытуның яңа ысулларын, чараларын табу, аларны куллану, дисплей кабинетлары җиһазлау һ.б.

Белем-тәрбия бирүнең яңа концепциясе төзелә, аларны

гамәлгә ашыру эше бара. Бу да педагогик эшчәнлеккә иҗади карауның бер күренеше.

Иҗадилык — укытучы-тәрбияче хезмәтенең төп нигезе. Бу эшне рәсми күрсәтмәләр белән чикләп тә, мәҗбүриләтеп тә булмый. Моңа укытучының нык әзерлеге, үз эшен белеп-бирелеп башкаруы, эшенә иҗади мөнәсәбәт булдыруы кирәк. Ләкин педагогикага яңалык башка фәннәргә һәм тармакларга караганда акрынрак керә. Бу хәлнең сәбәбе, бәлки, кешене укыту-тәрбияләүнең гаять дәрәҗәдә катлаулы булуындадыр. Кайбер яңалыклар, киң күләмдәге гамәли тәҗрибәләрдә раслан-мау сәбәпле, кире кагылалар яки тиз онытылалар. Педагогик технологиянең һәм техниканың хәзергә бик түбән дәрәҗәдә булуы да яңалыклар тудыруны тоткарлый.

Иҗади эшләүче укытучыларны шартлы рәвештә өч дәрәҗәгә аерып карарга мөмкин булыр.

Оста укытучы, һөнәр иясе. Андый укытучы психология, педагогика, методика фәннәрендәге яңалыкларны күзәтеп, өйрәнеп бара һәм галимнәрнең тәкъдимнәрен үз эшендә иҗа-ди куллана, халыкчанлыкны гамәлдә куллана белә. Шуның аркасында укыту-тәрбиядә башка укытучыларга караганда югарырак нәтиҗәләргә ирешә.

Яңалык кертүче укытучы — ул да оста укытучы. Ләкин эшендә фәндә тәкъдим ителгән алымнарны куллану белән генә чикләнми, тәҗрибәсен укыту-тәрбиянең нәтиҗәлелеген күтә-рүгә ярдәм итә торган яңа формалар, ысуллар, чаралар, яңа эчтәлек белән баета, халык педагогикасына нык таяна. Аның үзенә генә хас булган эш стиле барлыкка килә. Эш нәтиҗәсе дә югарырак була.

Эзләнүче-тикшеренүче укытучы. Бер үк вакытта ул оста да, тынгысыз да. Эшендә психология, педагогика, методика фәннәре тәкъдимнәрен иҗади куллану белән генә чикләнми, аларга нигезләнеп, үзе дә яңа эзләнүләр, фәнни-методик тик-шеренүләр үткәрә. Укыту-тәрбияне оештыруда яңалыклар кертеп, педагогиканы һәм методиканы баета, үстерә. Аның үз эш системасы барлыкка килә. Башка укытучыларны да шуңа өйрәтү мәктәбен оештыра. Андый укытучылар еш кына пси-хология, педагогика, методика фәннәреннән гыйльми дәрәҗә алуга да ирешәләр.

Бездә дә үз эшенең остасы булган укытучылар аз түгел. Шө-кер, яңалык кертүчеләр дә бар. Әмма хәзергә тикшеренү-эзләнү эшләре алып баручы укытучылар бер дә күп димәс идем. Ыша-набыз, киләчәктә укытучыга иҗади эшләү өчен мөмкинлек-ләр, тиешле шартлар булдырылыр, нәтиҗәдә яңалык кертүче һәм эзләнүче, тикшеренүче педагоглар саны да артыр. Монда, әлбәттә, фәнне һәм халыкчанлыкны берләштерү, халык педа-гогикасын ныграк куллану да яңа мөмкинлекләр ачар.

**РӘМИС НАСЫЙБУЛЛОВ,**
Татар дәүләт гуманитар-педагогика университеты-ның математика факультеты өлкән укытучысы.

*(Дәвамы бар.)*